РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУЗЯКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423734, село Кузякино,
ул. Советская,дом 28,
Тел. 3-44-48

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КҮҖӘКӘ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

423734, Күҗәкә авылы,
Совет ур., 28 нче йорт.
Тел.3-44-48

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**“19” декабрь 2023 ел** **№ 20**

**«Җир салымы турында» 2023 елның 13 декабрендәге 19 номерлы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге (икенче өлеш), “Күҗәкә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы, Актаныш муниципаль районының Күҗәкә авыл җирлеге карар итте:

1. «Җир салымы турында» 2023 елның 13 декабрендәге 23 номерлы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 п.3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- Россия Федерациясе Президентының “Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында” 2022 елның 21 сентябрендәге № 647 Указы (алга таба - мобилизация буенча гражданнарны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (ирләрен, балигъ булмаган балаларын һәм балаларын 23 яшькә кадәрге, мәгариф оешмаларында көндезге формада белем алучы 23 яшькә кадәрге балаларын) нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары;

1.2. п.3 түбәндәге эчтәлекле 10, 11, 12, 13, 14 абзацлар өстәргә:

-алар белән бергә яшәүче (билгеләнгән тәртиптә яшәү урыны буенча теркәлгән) мобилизация буенча чакырылган гражданнарның ата-аналарын;

- махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрби хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының (ире, балигъ булмаган балалары һәм 23 яшькә кадәрге, мәгариф оешмаларында көндезге формада укучы балаларның);

-алар белән бергә яшәүче (билгеләнгән тәртиптә яшәү урыны буенча теркәлгән) махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрби хезмәткәрләренең ата-аналары.

- махсус хәрби операциядә катнашучылар, шул исәптән махсус хәрби операция барышында хәбәрсез югалган һәлак булучылар;

- махсус хәрби операциядә (ире (хатыны), балигъ булмаган балалары, ата-аналары һәм хезмәткә сәләтсез башка иждивенецлар) катнашучыларның гаилә әгъзаларын);

2. Әлеге карар "Актаныш таннары" газетасында рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карар, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе** **И.Н.Мусин**